РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«31» октября 2022г.

с. Тюлячи

№ 226

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының ____________________________№ ___ карарына 1 номерлы кушымта

# Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасы

## ПАСПОРТ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасы |
| Программаны эшләүнең хокукый нигезләре | «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын комплексны профилактикалау стандарты |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) |
| Программаның максатлары | муниципаль контроль чараларын үткәргәндә контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының ачыклыгын арттыру;<br>юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуларны кисәтү;<br>закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын булдырмау;<br>закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау инфраструктурасын булдыру;<br>муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуга китерә торган гамәлдәге һәм потенциаль шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;<br>контрольлек итүче субъектларга административ йөкләнешне киметү; |

| | |
|---|---|
| | юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның социаль җаваплы, намуслы, хокукый тәртибе моделен булдыру |
| Программаның бурычлары | закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;<br>закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;<br>профилактик чараларның конкрет контроль субъектларның (объектларнын) һәм аларга хас хәвеф-хәтәр дәрәҗәсенең (куркыныч класслы) үзенчәлекләреннән бәйлелеген, рәвешләрен һәм интенсивлыгын билгеләү һәм бәяләү, әлеге факторларны исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү;<br>профилактик эш оештыру өчен кирәкле статистик мәгълүматларның төрләре исемлеген билгеләү һәм аларны җыю;<br>контроль органнарның кадрлар составының квалификациясен күтәрү;<br>контрольлек итүче субъектларга, шул исәптән заманча мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып, консультация бирү системасын булдыру;<br>җайга салына торган өлкә иминлегенең ачыкланган проблемаларына һәм профилактика эшенең агымдагы торышына бәйле рәвештә башка бурычлар. |
| Гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2023 ел һәм 2024 һәм 2025 еллар план чоры |
| Финанслау чыганаклары | Бюджет финанславы кысаларында |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын киметү;<br>Закон буйсынуындагы контроль субъектларынын өлешен арттыру<br>контроль органның профилактик чаралары системасын үстерү;<br>профилактиканың төрле ысулларын кертү;<br>контроль орган эчендә профилактик эш технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү; |

| | |
|---|---|
| | контрольлек итүче субъектларның нәтиҗәле, закон буйсынуындагы үз-үзләрен тоту үрнәкләрен эшләү;<br>контроль орган вазыйфаи затларының квалификацияле профилактик эшен тәэмин итү;<br>контроль орган эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген арттыру;<br>контроль астындагы субъектларга административ йөкләнешне киметү:<br>контроль астындагы субъектларның хокукый грамоталыгы дәрәҗәсен күтәрү:<br>контрольлек итүче субъектлар тарафыннан контроль предметын аңлауның бердәм булуын тәэмин итү;<br>контроль астындагы субъектларның намуслы тотышка мотивациясе;<br>башка |
| Программаның структурасы | Программа ярдәмче программаларны гамәлгә ашыруны күздә тотмый |

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасы

Әлеге программа Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын комплекслы профилактикалау Стандартын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде (алга таба текст буенча - муниципаль контроль).

Программа мәҗбүри таләпләрне үтәүгә комачаулый торган проблемаларны нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итә торган һәм мәҗбүри таләпләрне үтәмәүнең конкрет сәбәпләрен һәм аларны үтәмәү факторларын ачыклауга һәм бетерүгә, шулай ук профилактика системасын булдыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән проблемаларны нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итә торган профилактик чаралар комплексыннан гыйбарәт.

## I. Контрольдәге өлкәнең торышын анализлау һәм бәяләү

Теләче муниципаль районы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан күрсәтелә торган мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең җыелмасын үтәү муниципаль контроль предметы булып тора.

Контроль чаралары, аларны үткәрү буенча муниципаль контроль органы җитәкчесе тарафыннан раслана торган еллык план нигезендә, шулай ук, законнар нигезендә, оешмаларның һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәп, планнан тыш тикшерүләр рәвешендә үткәрелә торган планлы тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Контроль астындагы өлкә торышына мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча контроль астындагы субъектларны мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту һәм, нәтиҗә буларак, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү йогынты ясарга мөмкин.

Контроль астындагы өлкәдәге вәзгыятьне яхшыртуга контроль астындагы субъектларның җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хәбәрдарлык дәрәҗәсен күтәрүгә, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча үз вакытында чаралар күрүгә ярдәм итәргә мөмкин.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль контроль өлкәсендәге закон бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында мәгълүмат Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган.

Муниципаль контроль өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын үтәү максатларында: Теләче муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль контроль бүлегендә мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актлар исемлеге урнаштырылган, аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора.

## II. Профилактика эшен уздыруның максатлары һәм бурычлары

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2023-2025 еллар.

Муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру, мәгълүмати, хокукый һәм башка характердагы чараларны комплексы гамәлгә ашыру буенча системалы рәвештә оештырылган эшчәнлеге, ул түбәндәге төп максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

- муниципаль контроль чараларын үткәргәндә контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының ачыклыгын арттыру;
- юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуларны кисәтү;
- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын булдырмау;
- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау инфраструктурасын булдыру;
- муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуга китерә торган гамәлдәге һәм потенциаль шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;
- контроль астындагы субъектларга административ йөкләмәне киметү; юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның социаль җаваплы, намуслы, хокукый тәртибе моделен булдыру.

Профилактик чаралар үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салуга һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;
- закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерергә һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү;
- профилактик чараларның конкрет контроль субъектларның (объектларның) һәм аларга хас хәвеф-хәтәр дәрәҗәсенең (куркыныч классы) үзенчәлекләреннән бәйлелеген, әлеге факторларны исәпкә алып, профилактик чараларны үткәрүне билгеләү һәм бәяләү;
- профилактик эшне оештыру өчен кирәкле статистик мәгълүматларның төрләре һәм җыемнары исемлеген билгеләү;
- контроль органнарның кадрлар составының квалификациясен күтәрү; контроль астындагы субъектларга консультация бирү системасын булдыру, шул исәптән заманча мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып;
- җайга салына торган өлкә иминлегенең ачыкланган проблемаларына һәм профилактика эшенең агымдагы торышына бәйле рәвештә башка бурычлар.

Программаны гамәлгә ашыруның беренче этабы 2023 ел:

- муниципаль контроль өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм координацияләү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләү;

- профилактик эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

- үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булган норматив хокукый актларның яисә аларның мәҗбүри таләпләре булган аерым өлешләренең, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең текстларын актуальләштерү;

- мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән Теләче муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәү буенча ярдәмлекне әзерләү һәм урнаштыру юлы белән юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга хәбәр итү. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне, аларны гамәлгә кертү срокларын һәм тәртибен билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләр әзерләнә һәм таратыла;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган мәгълүматны ачу стандартларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерү;

- юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр планының Теләче муниципаль районының рәсми сайтында 2023 елга урнаштыру;

- уздырыла торган тикшерүләр һәм аларның нәтиҗәләре турында муниципаль контроль өлкәсендә контроль астындагы субъектлар (объектлар) реестрына мәгълүмат кертү;

- муниципаль контроль буенча хокук куллану практикасы буенча гавами фикер алышулар уздыру;

- муниципаль контрольне гамәлгә ашыру практикасын гомумиләштерү һәм анализлау, шул исәптән муниципаль контроль өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп, мондый хокук бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән;

- контроль астындагы субъектлар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү, мәҗбүри таләпләрне үтәү проблемалары буенча контрольлек итүче субъектларның фикерләрен ачыклау һәм исәпкә алу, муниципаль контрольнең профилактик эшчәнлегенең сыйфаты буенча һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең телефон, факсимиль, почта элемтәсе, электрон почта аша башка аспектларына карата, Теләче муниципаль районы сайтында кире бәйләнешнең электрон рәвешенә карата.

Программаны гамәлгә ашыруның икенче этабы (2024-2025 еллар)

- профилактик эшчәнлекне гамәлгә ашыруга якын килүне сыйфатлы яхшырту, киңәйтү һәм диверсификацияләү максатында профилактик эшчәнлекне аналитик тәэмин итү механизмнарын камилләштерү;

- комплекслы профилактика стандартында каралган барлык профилактика инструментларыннан файдалану;

- контроль-күзәтчелек эшчәнлеген башкаруның нәтиҗәлелегенә һәм эффективлыгына профилактик чараларның йогынтысын бәяләүне үткәрү.

## III. Инфраструктура булдыруга һәм профилактик эш башкаруга бәйле программа чаралары исемлеге һәм аларны гамәлгә ашыру графигы

Программалы чаралар аларны гамәлгә ашырганда барлыкка килергә мөмкин булган тискәре нәтиҗәләрне булдырмау буенча чаралар комплексын күздә тота.

Муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын кисәтүгә юнәлдерелгән муниципаль контрольнең профилактик чараларын оештыру һәм үткәрү җаваплы башкаручылар тарафыннан ел саен Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм раслана торган план-график нигезендә гамәлгә ашырыла.

| № тб | Чаралар исеме | Гамәлгә ашыру срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәҗбүри таләпләре булган норматив хокукый актлар исемлеген яки аларның аерым өлешләрен муниципаль контроль өчен Теләче муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру, аларның үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булып тора, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын | 2023-2025 ел | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга Теләче муниципаль районы территориясендә вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) |
| 2 | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре һәм башка ысуллар белән ярдәмлек әзерләү һәм бастырып чыгару юлы белән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат җиткерүне, консультация бирүне гамәлгә ашыру. Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта - гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне, аларны гамәлгә кертү срокларын һәм тәртибендә кертелгән үзгәрешләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләр әзерләү һәм тарату, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле оештыру, техник чаралар уздыру турында тәкъдимнәр | | |
| 3 | Муниципаль контроль эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә гамәлгә ашыру практикасын даими (елга кимендә бер тапкыр) гомумиләштерүне тәэмин итү. Теләче муниципаль районының рәсми сайтында тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыру, шул исәптән мондый хокук бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән зарури таләпләрне бозуның аеруча еш очрый торган очракларын күрсәтеп | | |
| 4 | «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирү (әгәр федераль закон белән башка тәртип билгеләнмәгән булса) | | |

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны гамәлгә ашырганда финанслау каралмаган.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге Программаның максатлары һәм бурычлары аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәле механизмнарын булдыру шартларында гына ирешелергә мөмкин.

Программаның координаторы булып Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары тора.

Программаны турыдан-туры үтәүчеләр булып Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тора.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җаваплылыкны Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тота.

Хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар бер елга профилактик эш йомгаклары турында хисап бирәләр.

Профилактика эшенең максатларына һәм нәтиҗәләренә ирешү өчен, шул исәптән Программаны гамәлгә ашыру һәм үз вакытында төзәтү максатларында, координатор программа чараларын гамәлгә ашыру дәрәҗәсен мониторинглауны һәм бәяләүне үткәрә.

## VI. Программа нәтиҗәлелеген бәяләү.

Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын профилактикалау программасын гамәлгә ашыруның төп ахыргы нәтиҗәсе булып 2023 елның гыйнварыннан 2025 елның декабренә кадәр чорда ачыкланган муниципаль контроль төрләре буенча законнар таләпләрен бозуларның саны кимү тора.

Профилактик чараларның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү түбәндәге индикатив күрсәткечләр буенча гамәлгә ашырыла:

- үткәрелгән профилактик чаралар саны, бер.;
- профилактик чаралар үткәрелгән контроль астындагы субъектларның саны, бер.

| № т.б. | 2023-2025 елга чара исеме | Саны, бер. |
|---|---|---|
| 1 | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | |
| 2 | профилактик чаралар үткәрелгән контроль субъектларының саны | |

2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына муниципаль контроль өлкәсендә закон тарафыннан сакланыла торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалау план-графигы

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | Планлаштырылган тикшерүләр турында контроль астындагы субъектларга мәгълүматны Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән хәбәр итү | Даими | Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Тикшерүләрне оештыру һәм уздыру мәсьәләләре буенча Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан контроль астындагы субъектларны кабул итү, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда законнар таләпләренең үтәлеше | Даими | Башкарма комитет |
| 3. | Контроль астындагы субъектларны гамәлдәге законнарны үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләү | Даими | Башкарма комитет |
| 4. | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нигезле практикасын Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру | Кимендә елга бер тапкыр | Башкарма комитет |
| 5. | Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган мәҗбүри таләпләре булган норматив хокукый актлар исемлеген актуаль хәлдә тоту, аларның үтәлеше муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшереп тору чараларын үткәргәндә бәяләнә. | Даими | Башкарма комитет |
| 6. | Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган, мәҗбүри таләпләре булган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшереп тору чараларын уздырганда үтәлүе бәяләнгән норматив хокукый актларның текстларын актуаль хәлдә тоту | Даими | Башкарма комитет |